**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**
09.07.2024

**БОЕРЫК**
№ 296

Казан

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2022 елның 6 сентябрендәге 369 номерлы «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан дәүләт бюджет гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкара торган башка максатларга субсидияләр бирүнең күләме һәм шартларын раслау турындагы» боерыгына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 06.09.2022 ел, 369 номерлы «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан дәүләт бюджет гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкара торган башка максатларга субсидияләр бирүнең күләме һәм шартларын раслау турындагы» боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары турында» сүзләренә алмаштырырга;

Күрсәтелгән боерыкта расланган гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан башка максатларга субсидияләр бирүнең күләме һәм шартларын раслау тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Рсепубликасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 06.09.2022 ел 369 номерлы боерыгы белән расланган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенең 4.1 пунктындагы икенче абзацы әлеге боерык редакциялегендә 2025 елның 1 гыйнварында үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Р.Н.Садыйков

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының 2022 елның 6
сентябрендәге 369 номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгы
редакциясендә)
____________ №_____)

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Рсепубликасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан башка максатларда билгеләнә торган субсидияләрнен күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе

I. Төп нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Рсепубликасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан( алга таба – Учреждение) әлеге тәртипнең 1.2. пунктында күрсәтелгән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының икенче абзацы нигезендә (алга таба – Тәртип) башка максатларда билгеләнә торган субсидияләрнен күләмен һәм шартларын билгеләү механизмын җайга сала.

1.2. Учреждениегә субсидияләр түбәндәге максатларда бирелә:

1642 номерлы 2017 ел 26 декабре Россия Федерациясенең карары белән расланган «Мәгариф үсеше» дәүләт программасын раслау турындагы» карары нигезендә расланган «Мәгариф үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасын, 16.10.2013 ел 764 номерлы «Иҗтимагый тәртипне тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору турындагы» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турындагы» карары белән расланган Татарстан Республикасы «Иҗтимагый тәртипне тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын, «Татарстан Республикасының икътисади үсеше һәм инновацион икътисад» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2013 ел 823 номерлы «Татарстан Республикасының икътисади үсеше һәм инновацион икътисад»Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турындагы» карары, Татарстан Республикасының 19.07.2014 ел 512 номерлы «Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы программасын раслау турындагы» карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.03.2019 ел 158 номерлы «Татарстан

Республикасында яшьләр сәясәте үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турындагы» карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.09. 2020 ел 821 номерлы «Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү турында» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган ««Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү турында» Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (алга таба-дәүләт программалары) гамәлгә ашыру кысаларында чаралар үткәрү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәләре кысаларында «Яшьләр өчен регион» Россия Федерациясе яшьләр сәясәтен комплекслы үстерү программаларының Бөтенроссия конкурсын уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган яшьләр сәясәтен комплекслы үстерү программасын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру.

1.3. Әлеге Тәртиптә файдаланылган төп төшенчәләр:

Чаралар – әлеге тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән яшьләр сәясәтенең комплекслы үсеш программалары, төбәк проектлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм Россия Федерациясе дәүләт программаларының процессы чаралары комплексы;

Субсидия – тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә акчаларны баш бүлүче һәм алучы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гамәлгә куючы тарафыннан учреждениегә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән чараларны гамәлгә ашыру кысаларында бирелә торган субсидия.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

## II. Субсидияләрне билгеләү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия алу максатларында Учреждение гамәлгә куючы адресына түбәндәге документларны үз эченә алган субсидия алуга гариза (алга таба – гариза) бирә:

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән максатларга субсидия бирү кирәклеген нигезләүне, субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне дә кертеп, шул исәптән чаралар үткәрүгә чыгымнарның башлангыч сметасын үз эченә алган аңлатма язуы;

чаралар программалары;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче числосына салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре,

пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы турында салым органы белешмәсе;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче числосына учреждениенең учреждение җитәкчесе һәм баш бухгалтер яисә башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычның булмавы турындагы белешмәсе.

Тапшырылучы документлар аңлаешлы итеп бастырылырга тиеш. Гариза учреждение мөһере белән (булган очракта) беркетелергә һәм вәкаләтле затның имзасы белән яисә учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланырга тиеш. Субсидия алуга документлар әзерләү буенча барлык чыгымнарны Учреждение тота.

Учреждение элек үзе биргән гаризаны таләп итәргә һәм аны кабат тапшырырга хокуклы.

Гариза учреждение тарафыннан электрон рәвештә бирелгән очракта бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасын кулланып, аларга учреждение җитәкчесе яисә учреждение җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручының электрон имзасы белән кул куелырга тиеш.

2.2. Гариза кергән көнне үк теркәлә. Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән алып 10 эш көне эчендә алардагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында Карар кабул итә.

2.3. Килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче числосына Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

Учреждениене үзгәртеп оештыру яисә бетерү чараларын гамәлгә ашыруга, авария (гадәттән тыш) хәл килеп чыккан очракта авария (гадәттән тыш) хәлне булдырмауга, нәтиҗәләрне бетерүгә һәм торгызу эшләрен башкаруга, законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычларны каплауга, шулай ук федераль законнарда,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш, учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы булмавы.

2.4. Учреждениегә субсидия билгеләүне кире кагу өчен нигез булып тора:

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

учреждение тапшырган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.5. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Учреждение әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган документларны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына кабат тапшырырга хокуклы.

2.6. Дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында чаралар үткәрү максатларында субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы закон белән билгеләнә.

Дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында чаралар уздыруга бәйле булмаган субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәләре белән билгеләнә.

2.7. Субсидияләр бирү нәтиҗәләре булып тора:

чараны гамәлгә ашыру – кимендә бер;

массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә чара турында язмалар саны – кимендә өч.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы-субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

2.8. Субсидия бирү турында Карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә куючы һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 маддәсендәге 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең үрнәк формасын раслау хакында»» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча субсидия бирү турында 1 пунктның икенче абзацы нигезендә шул исәптән түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алган килешү төзиләр:

чараның исемен күрсәтеп, субсидия бирүнең максатлары;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы;

субсидиянең размеры;

субсидии исәпләү срогы (графигы);

субсидия финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар турында хисаплылык, нәтиҗәләр күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын, иҗади хисапны гамәлгә ашыру турында хисаплылык тапшыру сроклары һәм тәртибе;

учреждение килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән гамәлгә куючыга субсидия бирүгә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта;

гамәлгә куючы карары буенча берьяклы тәртиптә килешүне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр, шул исәптән:

учреждениене үзгәртеп оештыру (кушылу рәвешендәге үзгәртеп оештырудан тыш) яисә юк итү белән;

учреждение тарафыннан әлеге Тәртиптә һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу;

учреждениенең килешүне берьяклы тәртиптә өзүен тыю.

Кирәк булганда гамәлгә куючы һәм Учреждение килешүгә Өстәмә килешү яисә килешүне өзү турында өстәмә килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк рәвешләр нигезендә төзи.

2.9. Гамәлгә куючы субсидияне тулы күләмдә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган учреждениеләрнең исәп-хисап счетларына субсидия күчерүнең килешүдә каралган графигы нигезендә күчерә.

## III. Исәп-хисап өчен шартлар

3.1. Учреждение гамәлгә куючыга хисапны түбәндәге срокларда тапшыра:
әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча хисап кварталыннан соң финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисапны алып баручы өч эш көненнән дә соңга калмыйча квартал саен;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында хисап, хисап кварталыннан соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча квартал саен;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап, хисап кварталыннан соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча квартал саен;

Тапшырыла торган хисап һәм теркәлә торган документлар аңлаешлы итеп бастырылырга тиеш. Төзәтүләр рөхсәт ителми, моңа учреждение мөһере белән беркетелгән (булган очракта) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган яисә учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтмәләр керми.

3.2. Гамәлгә куючы килешүдә өстәмә хисаплылык рәвешләрен һәм вакытларын билгеләргә хокуклы.

## IV. Субсидия һәм аларны бозган өчен җаваплылык бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе

4.1. Гамәлгә куючы һәм вәкаләтле дәүләт финанс контроле органы учреждениегә субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп тора.

Гамәлгә куючы субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү мониторингын субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен (контроль ноктасын) алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгалардан чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә һәм формаларда үткәрә.

4.2. Учреждение субсидия алу өчен яисә субсидиядән файдалану турында дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру, әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозу, шулай ук субсидияне тоту

максатларын бозу, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән хисапны тапшырмау өчен җаваплы.

4.3. Учреждение гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган субсидияне биргәндә билгеләнгән максатны һәм шартларны үтәмәгән очракта, субсидия учреждение гамәлгә куючының тиешле таләбен алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, субсидия учреждение Гамәлгә куючының тиешле таләбен алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.4. Учреждение әлеге Тәртипнең 4.3 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогын бозган очракта, гамәлгә куючы күрсәтелгән акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә Татарстан Республикасы бюджетына түләтү чараларын күрә.

4.5. Әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә билгеләнгән максатка ирешүгә агымдагы финанс елында файдаланылмый калган субсидия чаралары Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Гамәлгә куючы, учреждениенең агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрдән калган өлеше финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булу турындагы, субсидия бирү елыннан соң 20 эш көне дәвамында җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба-учреждениенең субсидиянең калган өлешләре буенча мөрәҗәгате) нигезендә, шулай ук учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуын һәм күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) нигезендә әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә, агымдагы финанс елында максатка ирешүгә тотылган субсидия акчаларының юнәлешенә ихтыяҗ булу турында Карар кабул итә.

Гамәлгә куючы субсидиянең агымдагы финанс елында файдаланылмаган калган акчаларын максатка ирешүгә юнәлтү ихтыяҗы булу турында карарны әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә учреждениедән субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгать алынган вакыттан алып биш эш көне эчендә кабул итә.

4.6. Гамәлгә куючының ихтыяҗ булу-булмавы турындагы карары нигезендә агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә максатка ирешүгә субсидия чараларының калган өлешен юнәлткәндә, күрсәтелгән субсидиянең калган өлеше агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә максатларга юнәлдерелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен файдаланылырга мөмкин.

4.7. Агымдагы финанс елында учреждение тарафыннан элек башкарылган, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалар булганда, учреждениенең финанс белән тәэмин итү чыганагы элек учреждение тарафыннан башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалар булган үтәлмәгән йөкләмәләре, шулай ук учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуын һәм күләмен раслый торган документлары

(документларның күчермәләре) булу турындагы субсидия бирү елыннан соң килүче елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба- учреждениенең элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалар буенча мөрәҗәгате) (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) нигезендә әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә билгеләнгән максатка ирешү өчен гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 1.2 пункты белән билгеләнгән максатка ирешү өчен учреждение тарафыннан алардан файдалану турында Карар кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында учреждение тарафыннан элек башкарылган, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән максатка ирешү өчен элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалар буенча учреждение мөрәҗәгать иткән вакыттан алып биш эш көне эчендә куллану турында Карар кабул итә.

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
Кушымта № 1
(Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының __________ _____номерлы боерыгы редакциясендә)

## Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре

| | | | КОДлар |
|---|---|---|---|
| | | Көне | |
| Учреждение исеме | ____________________ | Җыелма реестр буенча | |
| Гамәлгә куючы исеме | ____________________ | Җыелма реестр буенча | |
| Чара исеме, тибы | ____________________ | БК буенча | |
| | | Килешү номеры | |
| | | Килешү көне | |
| Документ төре | ____________________ (беренчел – «0», төгәлләштерелгән – «1», «2», «3», «...») | | |
| | | | |
| Ешлыгы: айлык, кварталлык, еллык | | | |
| | | ОКЕИ буенча | |

| Чыгымнар юнәлеше | | Субсидия бирү нәтиҗәсе | санау берәмлеге | | Юл коды | Килешүне гамәлгә ашыру еллары (сроклары) буенча субсидия бирү нәтиҗәләренең планлы күрсәткечләре | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | ____.____.20___ көненә | | ____.____.20___көненә | | ____.____.20___көненә | | ____.____.20___көненә | |
| исеме | БК буенча код | | исеме | ОКЕИ буенча код | | килешү төзелгән көннән | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | килешү төзелгән көннән | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | килешү төзелгән көннән | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | килешү төзелгән көннән | шулардан агымдагы финанс елы башыннан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат) ____________ __________ _________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Башкаручы ____________ __________ _________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза)

«__» ________ 20__ ел

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
Кушымта № 2
(Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының __________ ______номерлы боерыгы редакциясендә)

Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында
Хисап
«___» ___________ 20___ ел

Гамәлгә куючы исеме ____________________________________________________
Учреждения исеме____________________________________________________
Санау берәмлеге: рубль (икенче дистә билгегә кадәр төгәллек белән)

| Субсидия | | Агымдагы финанс елы башына субсидиянең калган өлеше | | Керемнәр | | | Түләүләр | | Курс аерымасы | Хисап чоры ахырына субсидиянең калган өлеше | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | БК буенча код | барлыгы | шулардан файдалануга рөхсәт ителгән | Барлыгы, шул исәптән | Татарстан Республикасы бюджетыннан | узган елларның дебиторлык бурычын кире кайтару | барлыгы | шулардан: Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылганнар | | Барлыгы | Шул исәптән: | |
| | | | | | | | | | | | шул ук максатларга юнәлештә таләп ителә | Кире кайтаруга дучар ителгән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат) ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Башкаручы ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза)

«__» _________ 20__ ел

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
Кушымта № 3
(Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының __________ ______номерлы боерыгы редакциясендә)

Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында
Хисап

| | | | КОДлар |
|---|---|---|---|
| | _______ 20__ ел. көненә | Көне | |
| | ____________________ | Җыелма реестр буенча | |
| Учреждение исеме | ____________________ | Җыелма реестр буенча | |
| Гамәлгә куючы исеме | ____________________ | БК буенча | |
| Чара исеме, тибы | | Килешү номеры | |
| | | Килешү көне | |
| Документ төре | ____________________ | | |
| | (беренчел – «0», төгәлләштерелгән – «1», «2», «3», «...») | | |
| Ешлыгы: айлык, кварталлык, еллык | | | |
| Санау берәмлеге: руб. | | ОКЕИ буенча | |

Бүлек 1. Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында мәгълүмат

| Чыгымнар юнәлеше | | Субсидия бирү нәтиҗәсе | | Санау берәмлеге | | Юл Коды | План күрсәткечләре | | Килешүдә каралган субсидия күләме | Факт буенча ирешелгән күрсәткечләр | | | | | | Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр күләме | | Финанс белән тәэмин итүнең файдаланылмаган күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | Хисап датасына | | План күрсәткеченнән чигенү | | Чигенү сәбәбе | | | | |
| исеме | БК буенча код | тибы | исеме | исеме | ОКЕИ буенча код | | килешү төзелгән көннән | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | | килешү төзелгән көннән | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | абсолют зурлыкларда | процентларда | код | исеме | йөкләмәләр | Акчалата йөкләмәләр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | | | | | | 0100 | | | | | | | | | | | | |
| | | | Шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | 0200 | | | | | | | | | | | | |
| | | | Шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | барлыгы: | | | | | | | барлыгы: | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат) ____________ __________ _________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Башкаручы ____________ __________ _________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза) (телефоны)

«__» ________ 20__ ел

Бүлек 2. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап кабул итү турында белешмәләр

| Күрсәткеч исеме | Россия Федерациясе бюджеты классификациясе коды | Субсидия Коды | КОСГУ | Сумма | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | килешү төзи башлаганнан | шулардан агымдагы финанс елы башыннан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән субсидия күләме | | | | | |
| | | | | | |
| Ихтыяҗы расланмаган субсидия күләме | | | | | |
| | | | | | |
| Объем субсидии, подлежащей возврату в бюджет | | | | | |
| | | | | | |
| Сумма штрафных санкций (пени), подлежащих перечислению в бюджет | | | | | |

Гамәлгә куючы җитәкчесе (вакәләтле зат) ____________ ____________________ ___________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Башкаручы ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза) (телефоны)

«__» ________ 20__ ел

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
Кушымта № 4
(Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының __________ _____номерлы боерыгы редакциясендә)

## Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы

| субсидия бирү нәтиҗәсе, үлчәү берәмлеге, контроль нокталар | | | | | План күрсәткече | Планга ирешү вакыты (дд.мм.гггг) | Статусы | Чигенү сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | коды | тибы | исеме | ОКЕИ буенча код | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Кабул итүче җитәкчесе (вәкаләтле зат) ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Башкаручы ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза) (телефоны)

«__» ________ 20__ ел

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкарган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
Кушымта № 5
(Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының __________ ______номерлы боерыгы редакциясендә)

## Субсидия (контроль пунктлар)бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында Хисап

| | | | КОДлар |
|---|---|---|---|
| | _______ 20__ ел. көненә | Көне | |
| | ______________________ | Жыелма реестр буенча | |
| Учреждение исеме | ______________________ | Жыелма реестр буенча | |
| Гамәлгә куючы исеме | ______________________ | БК буенча | |
| Чара исеме, тибы | ______________________ | Килешү номеры | |
| | | Килешү көне | |
| Документ төре | | | |
| | ______________________ | | |
| Ешлыгы: айлык, кварталлык, еллык | (беренчел – «0», төгәлләштерелгән – «1», «2», «3», «...») | | |
| | | ОКЕИ буенча | |

| Субсидияләр бирү нәтиҗәсе, контроль пунктлар | | | Санау берәмлеге | | Күрсәткече | | | Ирешү срогы (дд.мм.гггг.) | | Статусы | Чигенү сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | коды | тибы | исеме | ОКЕИ буенча код | План буенча | Факт буенча | Фараз буенча | План буенча | Факт буенча (фараз буенча) | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Субсидияләр бирү нәтиҗәсе | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Кабул итүче җитәкчесе (вәкаләтле зат) ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Башкаручы ____________ __________ __________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза) (телефоны)

«__» ________ 20__ ел